**СОВЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ул.Центральная, д.200, с. Качелино, Арский муниципальный район, 422013**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Үзәк урам, 200 нче йорт, Кәче авылы, Арча муниципаль районы, 422013**

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93 E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**«26» октябрь 2015 г.** **№ 6**

Кәче авыл җирлеге Советы
карары

Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Кәче авыл җирлеге башлыгы

"Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына таянып, Кәче авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Уставына Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 октябрендәге 19 номерлы карары (30.06.2015 елдагы 54 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

а) 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

« Әлеге статьяның 1 пунктындагы 14-15 пунктчалар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.»

б) 6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктны өстәргә:

13. Җирлек территориясендә яшәүче караучысыз хайваннарны тоту һәм тоту чараларын гамәлгә ашыру.»

в) 33 статьяда: - 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1. Җирлек Советы компетенциясендә:»; - 1 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;»

г) 69 статьяны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктта өстәргә:

«5. Муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»

д) 79 статьяны түбәндәге эчтәлекле 21 пунктны өстәргә:

«21. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турында карар, аның үтәлеше турында еллык хисап, җирле бюджет үтәлеше турында квартал саен белешмәләр һәм җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләр

хезмәткәрләренең саны турында фактик чыгымнарны күрсәтеп, рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.»

2. Әлеге карарны дәүләт теркәве өчен Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органының территориаль органына кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә җибәрергә.

3. Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башлыгына Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле вәкиленең территориаль органыннан кергән көннән җиде көн эчендә «Кәче авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында.

4. Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башлыгына Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы турында белешмәләр җибәрергә.

5. Шушы карарны тормышка ашыруны контрольдә тотуны Кәче авыл җирлегенең даими комиссиясенә йөкләргә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Т. Д. Закиров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КАЧЕЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609002656